Татарстан Республикасы Юстиция министрлыгы
№ 114од

Татарстан Республикасы дәүләт идарәсен цифрлы нигездә үстерү, мәгълүмати технологияләр һәм элемтә министрлыгы
№ п/145

БОЕРЫК
от 09.06.2022

«Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында» хокукый актларны рәсми бастырып чыгарганда үзара хезмәттәшлек регламентына үзгәрешләр кертү турында

«Татарстан Республикасы законнарын, Татарстан Республикасы Дәүләт Советы һәм аның Президиумы карарларын, Татарстан Республикасы Президенты, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты, Татарстан Республикасы башкарма хакимиятенең башка органнары норматив хокукый актларын рәсми бастырып чыгару һәм аларның үз көчләренә керү тәртибе турында» 2022 елның 29 апрелендәге 24-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы кабул ителүгә бәйле рәвештә боерабыз:

«Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталы»нда (http://pravo.tatarstan.ru) 2015 елның 18 маенда Татарстан Республикасы Юстиция министрлыгының 01-02/292 номерлы һәм Татарстан Республикасы мәгълүматлаштыру һәм элемтә министрлыгының П-70 номерлы уртак боерыгы белән расланган хокукый актларны рәсми бастырып чыгарганда үзара хезмәттәшлек регламентына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.2 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«1.2. Регламент «Татарстан Республикасы законнарын, Татарстан Республикасы Дәүләт Советы һәм аның Президиумы карарларын, Татарстан Республикасы Президенты, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты, Татарстан Республикасы башкарма хакимиятенең башка органнары норматив хокукый актларын рәсми бастырып чыгару һәм аларның үз көченә керү тәртибе турында» 2022 елның 29 апрелендәге 24-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы, «Татарстан Республикасы Президенты актларын әзерләү, бастырып чыгару һәм аларның үз көченә керү тәртибе, Татарстан Республикасы Президентына Татарстан Республикасы законнары проектларын бирү тәртибе турында» 2004 елның 2 июнендәге ПУ-431 номерлы Татарстан Республикасы Президенты Указы,

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карарларын һәм күрсәтмәләрен бастырып чыгару һәм аларның үз көченә керү тәртибе турында» 2002 елның 5 сентябрендәге 524 номерлы һәм «Республика башкарма хакимият органнарының норматив хокукый актларын әзерләү, аларны дәүләт теркәвенә алу һәм бастырып чыгару Кагыйдәләрен раслау турында» 2002 елның 18 июлендәге 426 номерлы карарлары нигезендә эшләнде;

2.1.3 пунктчаның икенче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Татарстан Республикасының цифрлы трансформация үзәге» дәүләт казна учреждениесе (алга таба - «ТР ЦТҮ» ДКУ)»;

түбәндәге эчтәлектәге 2.3 пунктны өстәргә:

«2.3. «Татарстан Республикасы законнарын, Татарстан Республикасы Дәүләт Советы һәм аның Президиумы карарларын, Татарстан Республикасы Президенты, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты, Татарстан Республикасы башкарма хакимиятенең башка органнары норматив хокукый актларын рәсми бастырып чыгару һәм аларның үз көченә керү тәртибе турында» Татарстан Республикасы Законының 5 статьясындагы 3 өлеше нигезендә Татарстан Республикасы Президентының, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының, республика башкарма хакимияте органнарының дәүләт серен тәшкил итүче белешмәләрен үз эченә алган актлары яисә күрсәтелгән актларның аерым нигезләмәләре, Россия Федерациясе законнары һәм Татарстан Республикасы законнары нигезендә игълан ителергә тиеш булмаган башка мәгълүматлар бастырып чыгарылырга тиеш түгел.»;

4.1 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«4.1. Татарстан Республикасы Юстиция министрлыгы Порталда Татарстан Республикасы Президенты Аппараты тарафыннан җибәрелгән Татарстан Республикасы законнарын һәм Татарстан Республикасы Президенты актларын, Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Аппараты тарафыннан җибәрелә торган Дәүләт Советы һәм аның Президиумы актларын, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты Аппараты тарафыннан җибәрелә торган Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты актларын Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнарының электрон документ әйләнеше бердәм ведомствоара системасы ярдәмендә pdf форматында урнаштыруны (бастырып чыгаруны) гамәлгә ашыра.»;

4.6 пунктының беренче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«4.6. «ТР ЦТҮ» ДКУ тәэмин итә:»;

5.1 пунктның икенче абзацын үз көчен югалткан дип танырга.

Татарстан Республикасы юстиция министры Р.И. Заһидуллин

Татарстан Республикасы дәүләт идарәсен
цифрлы нигездә үстерү,
мәгълүмати технологияләр һәм элемтә министры А.Р. Хәйруллин